КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 март г.Казань № 189

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмаларның Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге социаль әһәмиятле әдәбиятны электрон һәм басма төрдә басмага, бастырып чыгаруга һәм таратугага әзерләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 31 май, 414 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 4 сентябрь, 809 нчы; 2022 ел, 22 август, 873 нче; 2022 ел, 17 декабрь, 1363 нче; 2023 ел, 2 май, 550 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Оешмаларның Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге социаль әһәмиятле әдәбиятны электрон һәм басма төрдә басмага, бастырып чыгаруга һәм таратугага әзерләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә социаль әһәмияткә ия әдәбиятны басмага әзерләүгә, бастырып чыгаруга һәм таратуга бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Субсидияләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Цифрлы Татарстан» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2021 ел, 18 октябрь, 980 нче карары белән расланган «Цифрлы Татарстан» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасы

дәүләт телләрендә социаль әһәмиятле әдәбиятны электрон һәм басма рәвештә басмага әзерләүгә, бастырып чыгаруга һәм таратуга (алга таба – социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату) бәйле расланган чыгымнарны каплау максатларында юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) аларның оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә бирелә.»;

17 пунктның алтынчы абзацында «белешмә-мәгълүмат базасын яңарту» сүзләреннән соң «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтны модернизацияләү» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, республикада мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү, мәдәни-агарту программаларын булдыру һәм трансляцияләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 июль, 539 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 683 нче; 2021 ел, 23 сентябрь, 904 нче; 2022 ел, 22 август, 873 нче; 2022 ел, 11 ноябрь, 1198 нче; 2023 ел, 2 май, 550 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, республикада мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү, мәдәни-агарту программаларын булдыру һәм трансляцияләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, республикада мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат

формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү, мәдәни-агарту программаларын булдыру һәм трансляцияләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Субсидияләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Цифрлы Татарстан» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2021 ел, 18 октябрь, 980 нче карары белән расланган «Цифрлы Татарстан» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерүгә, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерүгә, республикада мәгълүмати технологияләр базарын үстерүгә, граждан җәмгыятен формалаштыруда ММЧ ролен арттыруга, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыруга һәм аны Россия Федерациясенең бөтен территориясендә һәм аннан читтә таратуга, халыкка күрсәтелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшыртуга һәм оперативлыгын арттыруга, Татарстан Республикасының ике дәүләт теленең тигез хокуклы булуын тәэмин итүгә, мәдәни-агарту программаларын булдыруга һәм трансляцияләүгә (алга таба – Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү) бәйле расланган чыгымнарны каплау максатларында юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) аларның оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә бирелә.»;

18 пунктның ундүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайтлар, Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү өчен кулланыла торган мәгълүмат ресурслары һәм сервислар булдыру, карап тоту, эшләвен тәэмин итү, модернизацияләү;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин